КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 декабрь г.Казань № 1159

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2000 ел, 21 июнь, 436 нчы; 2006 ел, 27 апрель, 211 нче; 2006 ел, 15 июнь, 303 нче; 2006 ел, 17 июль, 366 нчы; 2008 ел, 25 июль, 536 нчы; 2009 ел, 30 март, 192 нче; 2009 ел, 25 май, 333 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 879 нчы; 2011 ел, 23 май, 404 нче; 2011 ел, 21 декабрь, 1027 нче; 2012 ел, 06 февраль, 86 нчы; 2012 ел, 17 июль, 605 нче; 2012 ел, 20 декабрь, 1110 нчы; 2013 ел, 31 май, 367 нче; 2017 ел, 14 гыйнвар, 7 нче; 2017 ел, 13 сентябрь, 668 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу Нигезләмә (1.10 нчы пункттан тыш) җир кишәрлекләрен торгларда арендага бирү очракларына кагылмый.»;

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.6 – 1.11 нче пунктлар өстәргә:

«1.6. Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясындагы 2 нче пунктында каралган объектларны урнаштыру өчен, шулай ук җир асты

байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен бирелгән җир кишәрлекләренә аренда түләве федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган аренда түләве ставкалары белән исәпләнә.

1.7. Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{7}$ статьясындагы 5 нче пункты нигезендә аренда шартнамәсе төзелгән очракта, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләме мондый җир кишәрлегенә карата исәпләнгән җир салымы күләмендә билгеләнә.

1.8. Әгәр дә җир кишәрлегендә берничә файдалану төре гамәлгә ашырылса, аренда түләвен исәпләү максатларында, җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган иң зур төзәтү коэффициенты кулланыла.

1.9. Әгәр дә җир кишәрлекләрендә, бина, төзелмә, корылманың гомуми мәйданыннан иң күбе 20 процент булган мәйданлы офис инфраструктурасын (үзәкләштерелгән кабул итү бүлмәләрен, очрашулар үткәрү өчен бүлмәләрне, офис җиһазларын, парковкаларны кертеп) кулланып, җитештерү эшчәнлеге алып барылса, аренда түләве җитештерү эшчәнлеге өчен кулланыла торган ставка буенча алына.

1.10. Җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте үзгәргәндә аренда түләве җир кишәрлегенең кадастр кыйммәтенә үзгәреш кертелгән елдан соң килүче елның 1 гыйнвары хәленә карата яңадан исәпләнергә тиеш.

Җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте үзгәрүгә бәйле рәвештә, аренда түләвенә үзгәреш кертү мөмкинлеге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе белән күздә тотыла.

1.11. Әгәр дә Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастрында җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте билгеләнмәгән булса яисә 0 яки 1 сумга тигез күләмдә күрсәтелгән булса, аренда түләвен исәпләү җир кишәрлегенең базар кыйммәте нигезендә башкарыла.»;

2.3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

Җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган төзәтү коэффициентлары исемлеге

| Җир кишәрлегеннән файдалану төре | Коэффициент |
|---|---|
| Хәйрия фондларының медицина, социаль, психологик, юридик ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән биналары, төзелешләре һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,01 |

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2004 елның 27 декабрендәге ТРЗ-69 номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында төзелә торган торак һәм объектлар төзү өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,1 |
| Гражданнар авиациясе объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,1 |
| Махсуслаштырылган транспорт (тоткарланган транспорт чаралары) куеп тору урыннары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,1 |
| Чистарту корылмалары объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,1 |
| Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау учреждениеләрен-дә дәваланучы гражданнарның, озатып йөрүче затларның вакытлыча түләүсез яшәвенә билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,1 |
| «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге ФЗ-115 номерлы Федераль законга таянып төзелгән шартнамәләр, килешүләр нигезендә ясалуы, төзелеше, эксплуатациясе, реконструкциясе, модернизациясе гамәлгә ашырыла торган гидротехника корылмалары өчен (су мохите йогынтысына дучар булган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмау өчен күздә тотылган корылмалар (шул исәптән буалар, суташлагыч, сутөшергеч һәм су чыгара торган корылмалар); насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзлар; судно күтәргечләр; су басудан, сусаклагычлар ярлары, елга юлларының ярлары һәм төбе җимерелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмалар; киртәләү өчен корылмалар; дамбалар, ярларны ныгыту өчен корылмалар, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары; пирслар; техник су белән тәэмин итү корылмалары системалары корылмалары) | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 3 нче пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 25 нче пунктчасы нигезендә яки «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге ФЗ-115 номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чикләре булган җир кишәрлекләрендә төзелгән объектлар өчен | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 25 нче пунктчасына таянып төзелгән аренда шартнамәләре нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз акчасы һәм (яки) заем акчасы исәбеннән төзелә торган гидротехника корылмалары өчен (су мохите йогынтысына дучар булган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның | 0,1 |

| | |
|---|---|
| зарарлы йогынтысын булдырмау өчен күздә тотылган корылмалар (шул исәптән буалар, суташлагыч, сутөшергеч һәм су чыгара торган корылмалар); насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзлар; судно күтәргечләр; су басудан, сусаклагычлар ярлары, елга юлларының ярлары һәм төбе җимерелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмалар; киртәләү өчен корылмалар; дамбалар, ярларны ныгыту өчен корылмалар, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары; пирслар; техник су белән тәэмин итү корылмалары системалары корылмалары) | |
| Спорт объектлары һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 0,17 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектлары өчен | 0,5 (җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгәннән алып 5 ел вакыт белән) |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 1,0 |
| Торак урнаштыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача төзелеше өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Электр станцияләрен, аларга хезмәт күрсәтү корылмаларын һәм объектларын урнаштыруга билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Портлар, су, автоюл вокзалларын, аэровокзаллар урнаштыруга билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару, ясалма эшләнгән эчке су юлларын, причаллар, пристаньнар, автомобиль юллары өчен бүлеп бирелгән полосалар, су юллары, үткәргечторбалар, кабельле, радиорелейлы, һава элемтә линияләре һәм радиофикация линияләре, һава электр тапшыру линияләре, җир өсте һәм җир асты биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын эксплуатацияләү, карап тоту, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү өчен кирәкле объектлар, корылмалар һәм конструктив элементлар, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмалары өчен билгеләнгән объектлар; спутник элемтәсе инфраструктурасын һәм җир өсте корылмаларын урнаштыруга билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Склад объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Гаражлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Төзелеш чорында автомототранспортны куеп тора торган ябык күпкатлы урыннары өчен ( төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәген төзү» инвестиция проектын тормышка ашыру кысаларында булдырыла торган | 1,0 |

| | |
|---|---|
| объектлар төзү өчен (төзелеш чорын кертеп) | |
| Рекреация һәм дәвалау-савыктыру билгеләнешендәге объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 1,0 |
| Әйләнештәге су объектлары өчен | 1,0 |
| Скверлар, парклар урнашкан объектлар өчен | 1,0 |
| Башка объектлар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 2,0 |
| Административ биналар, урыннар һәм офислар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 2,0 |
| Автомототранспортны куеп тора торган ачык урыннар өчен (төзелеш чорын кертеп) | 3,0 |
| Күпләп сату объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 4,0 |
| Автосервис объектлары һәм автомобильләргә ягулык салу станцияләре өчен (төзелеш чорын кертеп) | 4,5 |
| Кунакханәләр өчен (төзелеш чорын кертеп) | 5,0 |
| Ваклап сату объектлары (кибетләр, сәүдә мәйданы булган павильоннар, аз-аз ваклап сату киосклары), базарлар, даруханәләр объектлары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 10,0 |
| Банк, иминият, биржа эшчәнлеге объектлары, шул исәптән түләү терминаллары өчен (төзелеш чорын кертеп) | 10,0 |
| Реклама объектлары (терәкләргә урнаштырылган реклама такталары һәм стендлар) өчен (төзелеш чорын кертеп) | 75,0». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин